ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

10.02.2022 № 25-од

г. Казань

«Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары нигезендә

боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсы (алга таба – Конкурс) турында нигезләмәне расларга.
2. «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең тематик соратуларны үтәү бүлегенә җаваплы башкаручыларны билгеләргә, расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә Конкурсны оештырырга һәм үткәрергә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016-2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган максатчан акчалар хисабына Конкурсның җиңүчеләренә һәм лауреатларына акча түләүне башкарырга.
4. «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студентлары арасында фәнни эшләр конкурсы турында» 2021 елның 26 мартындагы 56-од номерлы боерыкны үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының
10.02.2022 № 25-од
боерыгы белән
расланды

# Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен (алга таба - Стипендия) алуга «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсының (алга таба – Конкурс) максатларын һәм бурычларын, эчтәлеген, катнашучыларга карата таләпләрне, оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Стипендияне гамәлгә куючы - Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба - Дәүләт комитеты), Конкурсны оештыручы - «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Дәүләт архивы)

1.3. Конкурска тәкъдим ителә торган эшләрнең тематикасы архивларны өйрәнү, чыганакларны өйрәнү һәм / яки документларны өйрәнү өлкәсендә күрсәтелгән бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән булырга тиеш.

1.4. Әгәр Конкурска бер генә эш бирелсә һәм/яки бер эш тә бирелмәсә, Конкурс узмаган дип танылачак.

## 2. Максат һәм бурычлар

2.1. Конкурсны үткәрүнең төп максатлары түбәндәгеләр:

архивларны мәгариф киңлекләренә кертү;

фәнни-тикшеренү эшен башкаручы затларга ярдәм итү;

фән өлкәсенә яшьләрне җәлеп итү һәм көллият студентлары тарафыннан мөһим практик әһәмияткә ия архив документларына нигезләнеп башкарыла торган гамәли фәнни тикшеренүләрен стимуллаштыру.

2.2. Конкурсның бурычы – фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Архив фонды документларыннан файдалануны активлаштыру.

## 3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс турында мәгълүмат «Интернет» телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитеты рәсми сайтына эшләрне кабул итү башланганчы ун календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

3.2. Конкурста Казан төзелеш көллиятенең идарәне документлар белән тәэмин итү һәм архивны өйрәнү юнәлеше буенча тикшеренү белән шөгыльләнүче көндезге уку рәвешендә белем алучы (база әзерлеге программасы буенча) Казан төзелеш көллияте студентлары (алга таба – Катнашучы) катнаша.

3.3. Конкурста катнашучы эшләрдә күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен җаваплы була.

3.4. Катнашучылар ел саен 1 апрельгә кадәр Конкурска әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә күрсәтелгәнчә рәсмиләштерелгән тикшеренү эшен, әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада һәм 2 нче кушымтада каралган формалар буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны Столбище авылы, Совет урамы, 277 нче йорт адресы буенча урнашкан Дәүләт архивының кабул итү бүлмәсенә үзләре алып барып тапшыра һәм/яки prm.gart@tatar.ru электрон почтасы аша җибәрә.

3.5. Конкурска студентлар тарафыннан индивидуаль яки Дәүләт архивында архив практикасын узу барышында фәнни җитәкче җитәкчелегендә башкарылган эшләр кабул ителә. Катнашучы Конкурска эшне үз исеменнән тапшыра. Конкурс эше Катнашучының эштә билгеләнгән фәнни-тикшеренү бурычын хәл итүгә керткән шәхси иҗади өлешен чагылдырырга тиеш.

## 4. Конкурска куелган эшләргә карата таләпләр

4.1. Конкурс эше, мөстәкыйль һәм логик яктан төгәлләнгән эш булып, Конкурс тематикасына туры килергә һәм түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

уку йортының исеме, эш атамасы, эш авторының исеме, фамилиясе, атасының исеме, эшнең фәнни җитәкчесенең исеме, фамилиясе, атасының исеме, вазыйфасы, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме күрсәтелгән титул битен (булган очракта);

эшнең актуальлеген, яңалыгын, гамәли яки фәнни әһәмиятен, эш нәтиҗәләре буенча ясалган йомгакларны күрсәткән һәм аларны куллану мөмкинлегенә бәя биргән бер биттән дә артмаган күләмдәге кыскача аннотацияне;

төп сүзләрне;

эшнең актуальлеген, аның максатын һәм бурычларын, объектларын, предметларын, тикшеренү алымнарын һәм методикаларын нигезләүне үз эченә алган керешне;

эш нәтиҗәләрен апробацияләүне һәм (яки) гамәлгә кертелүен;

эштә күтәрелгән мәсьәләнең тарихын, бу өлкәдә тикшеренүләргә кыскача анализны һәм аларның нәтиҗәсен чагылдырган төп өлешне. Эшнең төп өлешендә тикшеренү объекты, предметы, алымнары җентекләп каралган, эштә китерелгән мәгълүматларны анализлау нигезендә нәтиҗәләр чыгарылган булырга тиеш;

эш буенча гомумиләштерелгән нәтиҗәләрне, тормышка ашыру нәтиҗәләрен (булган очракта), аларны конкурс юнәлешенә ярашлы рәвештә куллану мөмкинлеген бәяләүне үз эченә алган йомгакны. Эш темасы буенча публикацияләр (булган очракта) йомгак ахырында библиографик исемлек рәвешендә күрсәтелергә тиеш;

файдаланган әдәбият исемлеген;

кушымта рәвешендә өстәмә материалларны (кирәк булган очракта).

4.2. Конкурска тәкъдим ителә торган эш, таләп ителгән түбәндәге параметрларга туры китереп, текст редакторында башкарылган булырга тиеш:

А4 форматында;

битнең торышы – китап бите рәвешендә;

буш ара: өстән – 2 см, астан – 2 см, сул яктан - 3 см, уң яктан - 2 см;

шрифт – Times New Roman, зурлыгы - 14;

абзац: кызыл юл – 1,25 см, интервал – бер ярым.

4.3. Тәкъдим ителә торган эшнең күләме – кушымталарны исәпкә алмаганда, 15 биттән дә артык түгел. Битләрнең рәттән номерланган булуы мәҗбүри. Конкурска эш кәгазьдә тапшырыла һәм шулай ук prm.gart@tatar.ru электрон адресына җибәрелергә тиеш.

## 5. Авторлык хокуклары

5.1. Конкурста катнашучы Конкурска тәкъдим ителә торган материалларга махсус авторлык хокукларына ия булуын һәм, өченче затларның авторлык яки башка хокуклар белән якланган материалларыннан хокуксыз файдаланган очракта, өченче затлар алдында тулы җаваплылык тотуын гарантияли.

5.2. Дәүләт комитеты Конкурста катнашучыларның тематик документларын һәм тикшеренү эшләрен коммерциягә бәйле булмаган куллану хокукын үзендә калдыра.

## 6. Җиңүчеләрне билгеләү тәртибе, нәтиҗәләр чыгару

6.1. Стипендия Казан төзелеш көллияте дирекциясенең Конкурс комиссиясе (алга таба - Комиссия) карары нигезендә әзерләнгән тәкъдиме буенча Дәүләт комитеты тарафыннан бирелә.

6.2. 9 кешедән гыйбарәт Комиссия составы Дәүләт комитеты боерыгы белән ел саен 1 апрельгә кадәр төзелә һәм раслана. Комиссия составына Казан төзелеш көллияте вәкилләре - 5 кеше, Дәүләт комитеты һәм Дәүләт архивы вәкилләре (килешү буенча) - 4 кеше керә.

6.3. Комиссия Комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, секретареннан һәм әгъзаларыннан гыйбарәт. Комиссия эше белән рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаган очракта, вазыйфалар рәис урынбасарына йөкләнә.

Конкурс комиссиясе эше утырышта башкарыла. Комиссия утырышында әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул хокуклы дип санала.

6.4. Конкурс эшләрен бәяләү ике этапта үткәрелә.

Беренче этап: читтән торып. Конкурсның читтән торып үткәрелә торган этабында катнашучыларның эшләрен бәяләү Комиссия тарафыннан 10 баллы шкала буенча эксперт бәяләве алымы белән түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

тикшеренү проблемасы белән кыскача таныштыру сыйфаты, тикшеренү темасының актуальлеген аңлаешлы бәян итү – 0 алып 10 кадәр балл;

тикшеренү максатын, бурычларын билгеләү – 0 алып 10 кадәр балл;

файдаланылган архив һәм документаль чыганакларның күләме – 0 алып 10 кадәр балл;

тикшеренүләрнең үзе тарафыннан чыгарылган нәтиҗәләрен аңлаешлы бәян итү – 0 алып 10 кадәр балл.

Читтән торып катнашу этабы ел саен 15 апрельдән дә соңга калмыйча тәмамлана. Беренче этап нәтиҗәләре буенча иң күп балл җыйган 10 Конкурста катнашучы киләсе этапта катнашуга үткәрелә.

Икенче этап: барып катнашу. Икенче этап эшләрне Комиссия утырышында халык алдында яклау рәвешендә үткәрелә. Комиссия утырышны ел саен 1 майдан да соңга калмыйча билгели, анда катнашучыларның докладларын тыңлый, шуннан соң Комиссия Конкурсның җиңүчеләре һәм лауреатлары турында карар кабул итә.

6.5. Конкурсның барып катнашу этабында катнашучыларның эшләрен бәяләү Комиссия тарафыннан 10 баллы шкала буенча эксперт бәяләве алымы белән түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

бәян итү логикасы (фикерләүнең төгәллеге, нигезләмәләрнең эзлеклелеге, дәлилләнгән булуы, фикерләрнең ачыклыгы һәм бәян ителүенең кыскалыгы) – 0 алып 10 кадәр балл;

презентацияне куллануның нәтиҗәлелеге (иллюстрацияләрнең, күрсәтмә материалларның булуы, эш эчтәлеге ачылу/аны киңәйтү) - 0 алып 10 кадәр балл;

чыгыш ясау һәм дискуссия алып бару культурасы (сөйләме грамматик дөрес, үз-үзенә ышанган булу, аудитория белән элемтә урнаштыра алу, тышкы кыяфәте килешле булу) - 0 алып 10 кадәр балл.

6.6. Рейтингта беренче өч урынны алган катнашучы Конкурсның җиңүчеләре дип танылa. Калган катнашучылар Конкурс лауреатлары була.

Конкурсның берничә катнашучысы бертигез баллар санын җыйса, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

6.7. Комиссия карары Комиссия утырышы узганнан соң ике эш көненнән артык булмаган срокта беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия рәисе тарафыннан, ул булмаган очракта – Комиссия утырышында рәислек итүче Комиссия рәисе урынбасары тарафыннан имзалана һәм аңа Комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан, шулай ук утырышта катнашкан барлык Комиссия әгъзалары тарафыннан виза салына.

6.8. Конкурсның җиңүчеләре һәм лауреатлары исемлеге Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә Дәүләт комитеты боерыгы белән боерык имзаланган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмаган срокта раслана.

6.9. Конкурсның җиңүчеләре түбәндәге күләмдә стипендия ала:

1 урын өчен – 3 ай дәвамында ай саен 10 000 сум күләмендә түләнә;

2 урын өчен – 3 ай дәвамында ай саен 7 000 сум күләмендә түләнә;

3 урын өчен – 3 ай дәвамында ай саен 5 000 сум күләмендә түләнә;

Барып катнашкан этапның 7 кешедән артмаган лауреатлары 3 100 сум күләмендә бер тапкыр стипендия ала.

## 7. Стипендия алу тәртибе

7.1. Дәүләт комитеты Конкурсның җиңүчеләренә һәм лауреатларына Стипендияне, акчаны күчереп, сумнарда түли.

7.2. Стипендия түләнсен өчен Конкурсның җиңүчеләре һәм лауреатлары Дәүләт комитетына түбәндәге документларны тапшыралар:

шәхесне таныклый торган документ күчермәсен;

ИНН бирелү турында таныклык күчермәсен;

дәүләт пенсия иминиятенең иминият таныклыгы күчермәсен;

бүләкләүне күчерү өчен банктагы счет турындагы белешмәләрне (счет номеры, банк исеме, БИК һәм адресы).

7.3. Әлеге Нигезләмәнең 7.2 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру срогы - Конкурсның җиңүчеләре һәм лауреатлары билгеләгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча.

## 8. Финанслау

Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган максатчан акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитеты стипендиясен
алуга «Казан төзелеш
көллияте» дәүләт автоном
һөнәри белем бирү
учреждениесе студентлары
арасында ел саен үткәрелә
торган фәнни эшләр
конкурсы турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә рөхсәт

Мин ____________________________________________________________,
*Конкурста катнашучының ФИАи тулысынча (соңгысы – булган очракта)*
______________________________________________________________ укыйм,
элемтә өчен телефоным: ________________________________________________
Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсы үткәрелү кысаларында «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – Оператор), «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында каралганча, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә үземнең шәхси мәгълүматларымны автоматлаштыру чараларын кулланып эшкәртүгә, Оператор сайтларында (prm.gart@tatar.ru) казанышларым турында мәгълүмат урнаштыруга һәм Конкурс җиңүчеләре турында мәгълүмат урнаштыруга ризалык бирәм.

Моның белән Операторга шәхси мәгълүматларның түбәндә санап кителгән категорияләрен карый торган шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм:

1. ФИАи
2. Элемтә өчен телефон
3. Мәгариф оешмасы
4. Социаль статус

Шәхси мәгълүматларымны бары тик түбәндәге максатларда файдалануга ризалык бирәм:

- эшне төзү һәм эшкәртү;
- тапшырылган конкурс материалларын карау;
- статистика алып бару;
- Операторның рәсми сайтында конкурс нәтиҗәләрен чыгару;
- югарыда күрсәтелгән максатлар белән бәйле башка гамәлләр.

Минем сурәтләрне Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри

белем бирү учреждениесе студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсы үткәрелү кысаларында басма матбугатларда, интернет челтәрендә, радио- һәм телевизион эфирда урнаштырыла торган мәгълүмати һәм башка материалларда файдалануга ризалык бирәм.

Сурәтләрем минем намусыма, вөҗданыма һәм эшлекле абруема тап төшерә торган ысуллар белән файдалана алмый.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалык бирелгән вакытыннан алып вакыты чикләнмичә гамәлдә була һәм минем тарафтан, Операторга Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә гади язма рәвештәге гариза тапшырылып, кире алынырга мөмкин.

"___" _________, 20___ ел ____________________ ________________

(конкурста катнашучы имзасы) (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитеты стипендиясен алуга
«Казан төзелеш көллияте» дәүләт
автоном һөнәри белем бирү
учреждениесе студентлары
арасында ел саен үткәрелә торган
фәнни эшләр конкурсы турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

Таратырга шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,____________________________________________________________,
шәхси мәгълүматлар субъектының Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта) тулысынча

элемтә өчен телефон: ____________________, электрон почта адресы ____________________,

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясын нигез итеп алып, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә (ИНН 1655369841, ОГРН 1161690140809, урнашу урыны: Столбище авылы, Совет урамы, 277) (алга таба – Оператор) Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсын үткәрү кысаларында «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең рәсми сайтында минем хакта мәгълүмат урнаштыру максатларында минем шәхси мәгълүматларымны түбәндәге тәртиптә таратырга ризалык бирүем турында белдерәм:

| Шәхси м ә г | Шәхси мәгълүматлар исемлеге | Таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Чикләнмәгән затлар даирәсенә таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Шартлар һәм тыюлар | Өстәмә шартлар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | Фамилия | | | | |
| | Исем | | | | |
| | Атасының исеме | | | | |
| | Мәгариф оешмасы | | | | |
| | Социаль статус | | | | |
| Биометрик шәхси мәгълүматлар | Йөзнең төсле цифрлы фотография сурәте | | | | |

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматларыннан чикләнмәгән затлар даирәсе файдалана алачак һәм алар белән башка гамәлләр башкарылачак Операторның мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр:

| Мәгълүмат ресурсы | Шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр |
|---|---|
| h | Чикләнмәгән затлар даирәсенә бирү |

Әлеге ризалыкны үз ихтыярым белән бирәм һәм «__» ________, 20__ел алып « __» _________, 20__ ел кадәр гамәлдә була.

Шәхси мәгълүматларымны таратуны туктатуны таләп итү хокукы үземдә кала. Таләп куелган очракта, Оператор кичекмәстән минем шәхси мәгълүматларымны таратуны туктатырга, шулай ук шәхси мәгълүматлар тапшырылган өченче затлар исемлеген хәбәр итәргә тиеш.

| | | |
|---|---|---|
| дата | имза | фамилия, инициаллар |